ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ ГОРОДА
ИННОПОЛИС

ул. Спортивная, д.114, г.Иннополис,
Верхнеуслонский район,
Республика Татарстан, 420500

ИННОПОЛИС
ШӘҺӘРЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Спортивная ур., 114-нче йорт, Иннополис
шәһәре, Югары Ослан районы, Татарстан
Республикасы, 420500

тел. (843) 212-27-24, e-mail: city@innopolis.ru, www.verhniy-uslon.tatarstan.ru/rus/innopolis.htm

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
25.02.2020

г.Иннополис

КАРАР
06

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Иннополис шәһәре
Башкарма комитетына
гражданнардан кергән
мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү
тәртибен раслау турында

«Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 11 апрелендәге 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясы нигезендә Иннополис шәһәре Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Иннополис шәһәре Башкарма комитетына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Югары Ослан муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (http://verhniy-uslon.tatarstan.ru), Иннополис шәһәре мэриясе бинасында урнашкан махсус мәгълүмат стендында бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Иннополис шәһәре Башкарма комитетының документлар әйләнеше буенча баш белгеченә калдырам.

Җитәкче: Р.Р. Шагалеев

Иннополис шәһәре
Башкарма комитетының
2020 елның 25 февралендәге
6 номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Иннополис шәһәре Башкарма комитетына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү
Тәртибе

1. Әлеге Тәртип «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясын үтәү йөзеннән эшләнгән һәм Иннополис шәһәре Башкарма комитетына гражданнарның кергән мөрәҗәгатьләрен (алга таба - мөрәҗәгатьләр) гомумиләштерү һәм анализлау процедурасын билгели.

2. Иннополис шәһәре Башкарма комитетына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ ясау гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау буенча эш сыйфатын күтәрү, гражданнарның иҗтимагый фикерен һәм актуаль проблемаларын өйрәнү, шулай ук гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү рәвешләрен һәм методларын камилләштерү, аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау сыйфатын күтәрү максатларында үткәрелә.

3. Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен анализлау гражданнар мөрәҗәгатьләрен исәпкә алып, тиешле чорда кергән, шул исәптән язма рәвештә, электрон хәбәрләр рәвешендә, шулай ук Интернет-кабул итү юлы белән, гражданнарны шәхси кабул итү барышында һәм телефон аша җибәрелгән мөрәҗәгатьләрне исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

4. Кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау ел саен гамәлгә ашырыла.

5. Хисап чорыннан соң килүче айның 10 числосына кадәр гражданнарның мөрәҗәгатьләрен анализлау нәтиҗәләре буенча аналитик белешмә төзелә.

6. Аналитик белешмә үз эченә түбәндәге мәгълүматны алырга тиеш:
- кергән, адресланган һәм каралган мөрәҗәгатьләр, шул исәптән телдән һәм язма мөрәҗәгатьләр саны, электрон документ формасында мөрәҗәгатьләрне дә кертеп;
- мөрәҗәгатьләр структурасы һәм тематикасы;
- гражданнарны кабул итү урыннары, көннәре һәм сәгатьләре турында;
- шәхси кабул итү өчен җаваплы затларның шәхси кабул итүендә кабул ителгән гражданнар саны;
- гражданнарны шәхси кабул итү һәм шәхси күчмә кабул итү буенча вәкаләтле затлар турында;
- мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар, шул исәптән кабул ителгән норматив хокукый һәм башка актлар турында (булганда).

7. Аналитик белешмә Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында (http://verhniy-uslon.tatarstan.ru) хисап чорыннан соң килүче айның 15 числосына кадәр урнаштырыла.